| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ТАТАРСКО-КАНДЫЗСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАТАР КАНДЫЗЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.08. 2023 ел Татар Кандыз авылы №9

Баулы муниципаль районы
Татар Кандызы авыл җирлеге
территориясендә хуҗасыз хайваннарны
кайтару тыела торган урыннар
исемлеген раслау турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Татар Кандыз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Башкарма комитет Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге
КАРАР ИТЭ:

1. Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген кушымтага ярашлы рәвештә расларга.
2. Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибенә Татарстан Республикасы, Баулы районы, «Нефтяник-8» СНТ адресы буенча урнашкан «өйгә юл» автоном коммерциячел булмаган оешма белән хезмәттәшлекне тәэмин итәргә.».
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе М. Ш. Насыйбуллин